РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Решение Карар

13 декабрь 2023 ел **Чистай шәһәре** № 27/6

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 23 маендагы 44/3 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге N286-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 23 маендагы 44/3 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 6 статьясына (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2019 елның 26 сентябрендәге 47/3 номерлы, 2020 елның 20 гыйнварындагы 52/2 номерлы, 2020 елның 15 декабрендәге 3/7 номерлы, 2021 елның 11 августындагы 9/3 номерлы, 2023 елның 10 мартындагы 21/2 номерлы, 2023 елның 26 июлендәге 24/1 номерлы, 2023 елның 21 сентябрендәге 25/1 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 11 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- 17 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
- 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классль чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классль чиннар бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чистай муниципаль районы
Башлыгы Д.А. Иванов